**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

IV чакырылышның чираттан тыш утырыш

**КАРАРЫ**

29 декабря 2023 ел № 71 Урыссу ш.т.б.

2024 елга Ютазы муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның Фараз планын (программасын) раслау турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ Федераль закон, 2001 елның 21 декабрендәге «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында»гы 178-ФЗ санлы Федераль закон һәм Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2008 елның 30 маендагы 115 санлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы муниципаль милке белән идарә итү һәм аның белән эш итү тәртибе турында»гы нигезләмә нигезендә, «Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 94 маддәсенә таянып, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар итте:

1. Ютазы муниципаль районы муниципаль мөлкәтен 2023 елга хосусыйлаштыруның Фараз планын (программасын) кушымта нигезендә расларга.
2. 2024 елга Ютазы муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына «Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге мөлкәтен хосусыйлаштыруның Фараз планын (программасын) гамәлгә ашыруны тәкъдим итәргә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталын «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.
4. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Ютазы район Советының законлылык, регламент һәм җирлекләр советлары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Ютазы муниципаль районы башлыгы –
Татарстан Республикасы
Ютазы район Советы Рәисе А.Ә. Шәфигуллин

Татарстан Республикасы Ютазы
район Советының
«_29_»_декабрь 2023 ел №_71_
карары белән расланган

**2024 елга «Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның ФАРАЗЛАНГАН ПЛАНЫ (ПРОГРАММАСЫ)**

**I бүлек. 2024 елга муниципаль милекне хосусыйлаштыру бурычлары**

2023 елга муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның фаразланган планы (алга таба – хосусыйлаштыруның Фаразланган планы) 2001 елның 21 декабрендәге «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында»гы 178-ФЗ санлы Федераль закон, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ Федераль закон, «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге күчемсез мөлкәтне читләштерү үзенчәлекләре турында һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан арендалана торган күчемсез мөлкәтне читләштерү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы 2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ санлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2008 елның 30 маендагы 115 санлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы муниципаль милке белән идарә итү һәм аның белән эш итү тәртибе турында»гы нигезләмә нигезендә эшләнде.

Муниципаль мөлкәт белән идарә итү системасының базар икътисады шартларында төзелә торган өлеше буларак, 2023елда муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның төп бурычлары булып «Татарстан Республикасының Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары функцияләрен һәм бурычларын тәэмин итү өчен файдаланылмый торган муниципаль милек структурасын хосусыйлаштыру, шулай ук «Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 159-ФЗ санлы Федераль закон, 2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ санлы «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге күчемсез мөлкәтне һәм арендалана торган кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан читләштерү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында»гы Федераль закон таләпләрен гамәлгә ашыру тора.

2024 елда хосусыйлаштыруның төп максатлары булып тора:

- муниципаль милекне хосусыйлаштырудан район бюджетына салым булмаган керемнәр кертүне тәэмин итү;
- бюджетның керем өлешен арттыру;
- милекне карап тотуга район бюджетыннан чыгымнарны киметү.

«Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге икътисадында хосусыйлаштыру процессы нәтиҗәсендә структур үзгәрешләр түбәндәге сәбәпләр аркасында көтелми:

- хосусыйлаштыру өчен тәкъдим ителгән торак булмаган бинаны хосусыйлаштыруда милекче алышынганда муниципаль берәмлектәге икътисади вазгыятькә сизелерлек йогынты ясарга сәләтле производство урнаштырылмый;

Милекне сату исәбенә район бюджетына якынча 3000 мең сум алу планлаштырыла.

Хосусыйлаштыруның Фаразланган планы (программасы) нигезендә сатуга планлаштырылган объектның якынча бәясе базар бәяләвен үткәргәннән соң төгәлләштерелергә тиеш.

Хосусыйлаштырылырга тиешле объектның фаразланган бәясе базарның килеп туган конъюнктурасыннан чыгып исәпләнә.

2024 елда хосусыйлаштыру планлаштырыла торган мөлкәт исемлеге муниципаль милек структурасын алга таба оптимальләштерүне исәпкә алып тулыландырылырга мөмкин.

## II бүлек. 2024 елда хосусыйлаштыру планлаштырылган «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең муниципаль милке

| т/б | Исеме | Хосусыйлаштыру ысулы | Фаразланган сату вакыты |
|---|---|---|---|
| | Автотранспорт чаралары, 7 берәмлек | ачык аукцион | 2 квартал |